# ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**О внесении изменения в статью 8**
**Экологического кодекса Республики Татарстан**

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
3 ноября 2016 года

**Статья 1**

Внести в абзац двадцать второй части 1 статьи 8 Экологического кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2009, № 1; 2010, № 5 (I часть); 2011, № 6 (I часть), № 10 (I часть); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2; 2016, № 5) изменение, изложив его в следующей редакции:

«организация использования лесов, их охраны (в том числе осуществления мер пожарной безопасности и тушения лесных пожаров, за исключением выполнения взрывных работ в целях локализации и ликвидации лесных пожаров и осуществления мероприятий по искусственному вызыванию осадков в целях тушения лесных пожаров), защиты (за исключением лесозащитного районирования и государственного лесопатологического мониторинга), воспроизводства (за исключением лесосеменного районирования, формирования федерального фонда семян лесных растений и государственного мониторинга воспроизводства лесов) на землях лесного фонда и обеспечение охраны, защиты, воспроизводства лесов (в том числе создание и эксплуатация лесных дорог, предназначенных для использования, охраны, защиты и воспроизводства лесов) на указанных землях;».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Президент
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК

Казань, Кремль
19 ноября 2016 года
№ 87-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 3 ноябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясындагы 1 өлешенең егерме икенче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2; 2016, № 5), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

"урман фонды җирләрендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны (шул исәптән янгын куркынычсызлыгы чараларын гамәлгә ашыруны һәм урман янгыннарын сүндерүне, моңа урман янгыннарын локальләштерү һәм туктату максатларында шартлату эшләрен башкару һәм урман янгыннарын сүндерү максатларында явым-төшемнәрне ясалма булдыру чараларын күрү керми), яклауны (урманны яклауны районлаштырудан һәм дәүләт урман патологиясе мониторингыннан гайре), торгызуны (урман орлыкларын районлаштырудан, урман үсемлекләре орлыкларының федераль фондын булдырудан һәм урманнар торгызылуга дәүләт мониторингыннан гайре) оештыру һәм күрсәтелгән җирләрдә урманнарны саклауны, яклауны, торгызуны (шул исәптән урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау һәм торгызу өчен билгеләнгән урман юлларын булдыруны һәм эксплуатацияләүне) тәэмин итү;".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты　　　　　　　　　　Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 19 ноябре
№ 87-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ